РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь 2023 ел Буа шәһәре № 6-56

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Советының 2021 елның 22 ноябрендәге 1-21 номерлы
карары белән расланган Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районында муниципаль торак контроле
турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигездә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 22 ноябрендәге 1-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль торак контроле турында (алга таба - Нигезләмә) нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 нче кушымтасын, 1 нче кушымта нигезендә, үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

2. Әлеге карарны Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы вазыйфаларын
башкаручы, Совет рәисе урынбасары И.Ф.Еремеев

ТР Буа муниципаль районы Советының
2023 елның 15 декабрендәге 6-56 номерлы карарына
1 нче кушымта

« ТР Буа муниципаль районы Советының
2021 елның 22 ноябрендәге 1-21 номерлы карарына
3 нче кушымта

Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.
2. Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булган граждан яисә оешмаларның күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булып торучы оешмалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, массакүләм мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән мәгълүмат, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны контрольдә тотучы затлар тарафыннан тикшереп торыла торган фактлар турында мәгълүмат системасы таләпләрен бозуның фактлары хакында ачыкланган календарь елының алдагы чоры белән чагыштырганда вакыт берәмлеге (ай, квартал) өчен мөрәҗәгатьләр санының өч мәртәбә һәм аннан күбрәк үсеше.
3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 5 өлеше нигезендә билгеләнгән урнаштыру тәртибе, рәвешләре, сроклары һәм вакыты нигезендә урнаштырылырга тиешле мәгълүматны өч һәм аннан артык ай дәвамында актуальләштерүнең булмавы.
4. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматы буенча контрольдә тотылучы зат идарәсендәге күпфатирлы йортта гомуми милекнең төзексезлеген бетерү эшләрен уздыру өчен ремонт бригадаларын атнага биш тапкыр чакыру.
5. Алдагы хисап чоры белән чагыштырганда 50%тан артыгракка торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә түләү документларында күпфатирлы йорт биналары милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм карап торганда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен арттыру турындагы белешмәләрне күрсәтү,

___